**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«НОВОТРОИЦК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«09» декабря 2024 ел № 54/4

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү системасы турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советының 2023 елның 21 февралендәге 28/2 номерлы карарына өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары (2018 елның 24 апрелендәге 281 номерлы, 2018 елның 14 июнендәге 481 номерлы, 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы, 2018 елның 29 декаберендәге 1320 номерлы, 2021 елның 17 ноябрендәге 1087 номерлы, 2021 елның 13 декабрендәге 1222 номерлы, 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы, 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы, 2024 елның 24 июнендәге 451 номерлы, 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), авыл җирлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү системасы турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советының 2023 елның 21 февралендәге 28/2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 1 пунктчасында «13 323 саннарын «13 990» саннарына алыштырырга;

2 бүлек 1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затның (җирлек башлыгы) хезмәтенә түләү айлык акчалата бүләкләү формасында башкарыла:

| Вазыйфа исеме | Акчалата түләү күләме (сумнарда) | Акчалата кызыксындыру түләве (сумнарда) |
|---|---|---|
| Җирлек башлыгы | 22810 | 28969 (15.24) |

2 бүлек 2 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 4 пунктчаны өстәргә: «Эш нәтиҗәләре буенча айлык акчалата түләүнең 10% күләмендә премия»;

4 бүлек 2 пунктта «13 323» саннарын «13 990» саннарына алыштырырга, «2024 елның 1 июленнән» сүзләрен «2025 елның 1 гыйнвареннән» сүзләренә алыштырырга;

4 бүлек 3 пункт 1 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

| **Вазыйфа исеме** | **Хезмәткә түләүнең 10 төркеме** |
|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 22 804 |
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары | 22 385 |
| Әйдәп баручы белгеч | 15 529 |
| 1 категорияле белгеч | 13 990 |

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнвареннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Д.М. Габделхаева